| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

с.Степная Шентала

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**24.06.2026** **№ 19**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Идел буе транспорт Прокуратурасының 03.06.2026 ел №23/1-2-2026 протестын үтәү йөзеннән, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталы авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының 14.08.2023 ел, № 47 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә, түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

1) 38 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктында «һәм тимер юл транспортының контакт челтәрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 56 статьяның 1 өлешендә «тимер юл транспортының контакт челтәре таянычы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 56 статьяның 4 өлешендә «һәм тимер юл транспортының контакт челтәре таянычлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында,Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Кыр Шонталы авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет рәисе** **Г.Н.Кыямова**